КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 30 ноябрь г.Казань № 1067

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен 2018 елгы премияләрен бирү турында

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен премияләрен бирү советы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Продукциянең һәм хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты, аларның иминлеген тәэмин итү өлкәсендә шактый зур нәтиҗәләргә ирешкән, шулай ук сыйфат белән идарә итүнең югары нәтиҗәле ысулларын керткән өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен 2018 елгы премияләрен «Эшлекле камиллек» номинациясендә түбәндәгеләргә бирергә:

эшчәнлекләрен җитештерү билгеләнешендәге продукция һәм (яки) халык кулланauthor товарлары җитештерү өлкәсендә гамәлгә ашыручы, эшләүчеләр саны 250 кешедән артык булган предприятиеләр һәм оешмалар категориясендә – «Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционерлар җәмгыятенә (Түбән Кама шәһәре);

эшчәнлекләрен хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә гамәлгә ашыручы, эшләүчеләр саны 250 кешедән артык булган предприятиеләр һәм оешмалар категориясендә – Казан шәһәренең «16 нчы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә (Казан шәһәре);

эшчәнлекләрен хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә гамәлгә ашыручы, эшләүчеләр саны 250 кешедән артмаган предприятиеләр һәм оешмалар категориясендә – «Алабуга политехника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә (Алабуга шәһәре), Казан шәһәренең «10 нчы шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә (Казан шәһәре);

«Җитештерү системалары» номинациясендә:

«Система-Сервис» идарә итүче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә (Әлмәт шәһәре), өстәмә һөнәри белем бирүче «Кадрлар әзерләү үзәге – Татнефть» шәхси мәгариф учреждениесенә (Әлмәт шәһәре).

2. Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен премияләрен бирү советына Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен 2018 елгы премияләренә дәгъва итү конкурсы лауреатларын һәм дипломантларын бүләкләү тантанасын әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин